# ДУСЛАРГА

*З.НАГАЕВА шигыре һәм көе*

Җаннар сары, сагыш тулы күзләре бар,
Дусларымның яз күтәреп килгәне бар.

*КУШЫМТА:*
Әйләнә дә килә җәйләр,
Әйләнә дә килә язлар,
Китә читләр, китә ятлар,
Янда кала тугры дуслар.

Адашырлык салкыннарга кергәнем бар,
Дусларымның җылы бирер йөрәге бар.

Учак ягып җылынырлык дусларым бар,
Дусларым, дип, өзелеп җырлар җырларым бар.